| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 27 декабрь г.Казань № 1225

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар үткәрүгә бәйле булган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 29 сентябрь, 873 нче карары белән расланган Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар үткәрүгә бәйле булган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар үткәрүгә бәйле булган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 29 сентябрь, 873 нче карары белән (Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 29 декабрь, 1281 нче; 2019 ел, 5 февраль, 70 нче; 2019 ел, 22 август, 699 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар үткәрүгә бәйле булган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 нче пунктта:

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

чаралар үткәрү өчен биналарны, яссы корылмаларны һәм җайланмаларны ремонтлау;

күнегүләр чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.»;

15 нче пунктта:

беренче абзацта «субсидия күләме» сүзләрен «субсидия күләме (С)» сүзләренә алыштырырга;

дүртенче абзацны төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин